
Хәлим Җәләй
Пәриле
кул
буенда

Хәлим Җәләй



Пәриле күл буенда

әкиятләр

Казан ✧ Татарстан китап нәшрияты ✧ 2006

УДК 821.512.145-34-1-93
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
Ж84

Рәссамы Алла Айсина

Җәләй Х.Б.

Ж84 Пәриле күл буенда: Балалар өчен әкият-поэмалар / Хәлим Җәләй. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 40 б.

ISBN 5-298-03944-8

Укучыларга халкыбызның «Шәрә бүре», «Турай батыр», «Корчаңгы тай һәм таз малай» әкиятләре буенча язган әкият-поэмалары аша таныш булган Хәлим Җәләй бу яңа китабында нәни дусларына тагын ике яңа әкиятен тәкъдим итә.

ISBN 5-298-03944-8

© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Җәләй Х.Б., 2006

ПӘРИЛЕ
КҮЛ БУЕНДА

(Әкият-поэма)

Борын-борын заманда,
Теше китек команда;
Яман эшләр, яхшы эшләр
Мәш килеп буталганда,

Әллә нинди әкәмәтләр,
Кызык хәлләр бар икән;
Сөйләсәң, кеше ышанмас –
Дөрес микән, юк микән:

Бүреләр үлән ашый, ди,
Керпеләр су ташый, ди,
Төлкенең сырты кычытса,
Тавык килеп кашый, ди.

Ишәк базарчы икән,
Аю азанчы икән.
Куян сабанчы икән,
Бурсык казанчы икән.

Каз-үрдәкләр җыйнаулашып
Җырлап йөриләр икән.
Песиләр ишегалдында
Карны көриләр икән.

Әйтәм ич, бик кызык хәлләр
Булган, ди, ул заманда.
Бәйрәмнәрдә, хуш ис бөркеп,
Ботка пешкән казанда.

Тамаклары тук икән,
Кайгылары юк икән.

Шушындый сәер заманда
Яшәгән, ди, бер кеше.
Булган аның өч улы һәм
Авызында өч теше.

2 3-318

Ярлының да ярлысы, ди,
Фәкыйрь белән бер чама.
Бар байлыгы – үткен балта,
Әтисеннән калган көрәк
Һәм бер капчык мунчала.

Еллар үтә, картая бу,
Үләр вакыты җитә.
Әҗәл килгәч, үз янына
Улларын дәшеп кертә.

– Бәхил булыгыз, улларым,
Мин инде озак тормам.
Бар байлыкны мирас итеп
Сезгә калдырмак булам:

Олы улым, сиңа балта,
Уртанчы улга көрәк.
Төпчек улыма мунчала –
Гадел булырга кирәк.

Соңгы сүзләрен әйткән дә
Мәңгегә күзен йомган.
Урыны җәннәттә булсын,
Шулай җан тәслим кылган.

Әтиләре вафат булгач,
Болар ятим калалар.
Өчесе дә кулларына
Әтиләре васыять иткән
Мирасларын алалар.

– Үз көнемне күрермен, – дип,
Балтасын кулга алып,
Олы улы сәфәр чыга,
Биштәрен иңгә салып.

Бара торгач барып җитте
Зур гына бер авылга.
Бик сәер хәл: бер балта да
Юк икән, ди, авылда.

Бер бай кеше йорт салдырган,
Юк, ди, килмәгән төше.
Тик тәрәзә уйдырмаган,
Кояш нуры төшмәгәнгә
Дөм караңгы өй эче.

Бай кешенең байларча шул –
Әмәлен тапмас димә.
Хезмәтчеләр көне буе
Иләк белән, чиләк белән
Якты ташыйлар өйгә.

Әмма соң яктылык кайда?!
Эш һич салынмый җайга.
Балталы егет шул чакта
Әйтә икән бу байга:

– Өеңә кояш яктысы
Кертәм, әгәр теләсәң.
Хезмәтем өчен бәяне
Тиешенчә түләсәң.

– Күпме сорасаң да сора,
Бөтен шартыңа күнәм.
Иртәдән алып кичкәчә
Өй эчендә якты булса
Мең тәңкә акча бирәм.
Син ризамы?
– Мин бик риза!
Ике як та килешә.
Балтасын кулына алып,
Егет эшкә керешә.

Бай өенең өч ягына
Алты тәрәзә уйган.
Тәрәзәләр көлеп тора,
Кайдан гына юнәткәндер,
Пыяласын да куйган.

Өй эче ялт итеп киткән,
Бөтен җиргә нур кергән.
Шатлыгына түзалмыйча,
Бай абзый мең сумга өстәп
Тагын йөз тәңкә биргән.

Кулга шундый акча төшкәч,
Егетебез сөенә.
Пар ат җигеп, күп мал җыеп,
Бер бай кызына өйләнеп,
Кайтып керә өенә.

Уртанчы малай кызыга,
Абыйсы баеп кайткач.
Хыяллана, план кора,
Кичен йокларга яткач.

– Әти миңа бу көрәкне
Зерәгә бирмәгәндер,
Олы абый күк минем дә
Баюны теләгәндер.

Ходай кушса, таң аткач та
Сәфәргә кузгалырмын.
Ни мәшәкатьләр күрсәм дә
Сер бирмәм, түзалырмын.

Татлы хыялга батып,
Кичтән йокыга ятып,
Икенче көн таң белән
Көрәген иңгә сала,
Кулга бер таяк ала,
Тәвәккәлләп, бәхет эзләп,
Сәфәргә дип кузгала.

Иртә китә, кич китә,
Саплам буе җир үтә;
Бара торгач, зур гына бер
Авылга барып җитә.

Бу авылның уртасыннан
Зур елга аккан икән.
Әмма салкын кышка кергәч,
Калын боз каткан икән.

Авылның бөтен кешесе
Боз өстенә чыкканнар;
Авыл белән өмә ясап
Бик күп ашлык сукканнар.

Тик ашлыкны суккан чакта
Арттырып җибәрәләр –
Әллә кешеләре надан,
Әллә акыллары таман –
Кул белән җилгәрәләр.

Халык эшли янып-пешеп,
Аптырыйлар, тирлиләр.
– Бер айсыз да бу ашлыкны
Эш итеп булмас, – диләр.

Бераз вакыт карап торгач,
Болар янына килеп,
Безнең егет сәлам бирә,
Сүз башлый болай диеп:

– Ходай ярдәм итсен сезгә,
Эшегез бармый, күрәм.
Хакын яхшы түләсәгез,
Ашлыгыгызны бер көндә
Шәпләп җилгәреп бирәм.

– Зинһар, ярдәм итче, егет,
Бәясеннән тормабыз,
Килешкәнеңне алырсың,
Вәгъдәбезне бозмабыз.

Егетнең көрәге җайлы,
Шундук керешә эшкә.
Үзе дә бик нык тырышкач,
Җай искән җил дә булышкач,
Эш тәмам була кичкә.

Сөйләшкән бәяне алгач,
Таслап кесәгә салгач,
Бик күп рәхмәтләр ишетеп,
Тагын килергә килешеп,
Егет юлга кузгала,
Авылына юл ала.

3 3-318

Уйнап торган пар ат җигеп,
Фаэтонга кырын ятып,
Бер атнадан кичкә таба
Авылга керә кайтып.

Өр-яңа йорт сатып ала,
Күргән кеше хәйран кала;
Бай кызына өйләнә –
Моның тормыш көйләнә.

Абыйлары баеп кайткач,
Төпчек малай кызыга:
– Баесам, яучы җибәрәм
Мин дә бер бай кызына.

Әти калдырган мунчала
Ярар кәсеп итәргә.
Иртәгә иртүк таң аткач,
Бәхет сынап, ерак юлга
Кирәк чыгып китәргә.

Иртән, Аллага тапшырып,
Сәфәргә дип кузгала.
Кояш төшлеккә җиткәнче
Шактый гына юл ала.

Тамак ялгап, ятып алгач,
Сәфәрен дәвам итә.
Икенче көн кичкә таба
Бер күлгә барып җитә.

Бу күлнең зурлыгын күреп,
Егет аптырап кала.
– Ни булса, шул булыр, – диеп
Юнәлә күлгә таба.

Күлнең чите – куе камыш
Каплап торган яр икән.
Күл төбендә мыжгып торган
Җен-пәриләр бар икән.

Егет бераз шүрләп кала,
Аннан биштәрен сала.
Бик зур эш майтарган кебек,
Кулга мунчала ала.

Ярда үскән бер агачның
Юан ботагын сайлап,
Шуңа очын бәйли дә бу,
Ишә дә башлый җайлап.

Мунчаладан юан аркан
Ишә тирләп-тырышып.
Биш-алты колач ишкәчтен,
Суга тыга бер очын.

Бер пәри малае судан
Чыккан да карап тора.
Егетнең һич исе китми,
Хәйлә тозагын кора.

Пәри малае аптырый,
Челт-челт килә күзләре.
Шүрләп кенә, калтыранып
Көчкә чыга сүзләре.

– Абый, безнең күл янында
Аркан ишәсең нишләп?
– Менә күлегезне күккә
Асып куярга исәп.

Шулай диюгә, сикерә,
Күлгә чума бу малай.
Бабасы янына чаба:
– Харап булдык без, бабай!
Берәр чарасын уйлап тап,
Асалар күлебезне.
Оябызны туздыралар,
Куалар үзебезне!

– Син курыкма, бавын үлчә,
Озын микән, нык микән;
Күккә кадәр җитәрлекме,
Чыдарлыкмы, юк микән?

Аннан, улым, аның белән
Сез көрәшеп карагыз.
Көрәшкәндә тиңсез иде
Сезнең Дию бабагыз.
Җиңсәң, күлне үзебездә
Калды диеп санагыз.
Ул чагында эш җайланыр,
Котылу җаен табабыз.

Чыга малай яр читенә:
– Әйдә көрәшик, агай.
– Көрәшербез, бездән калмас,
Ашыкма, энем, алай.

Ә-ә-нә шул куак төбендә
Ял итә минем бабай.
Аны җиңсәң, минем белән
Көрәшеп кара давай.

Пәри малае ничек тә
Җиңәргә дип баш вата.
Зур гына таш табып алып
Куакка төбәп ата.

Куак артыннан шул заман
Аю чыга үкереп.
Аңгыра пәри малаен
Чыркылдатып җиргә бәрә,
Чак ташламый үтереп.

Сынган сөякләрен сөйрәп
Көчкә котылды качып;
Бабасы янына чапты,
Сөйли башлады шашып:

– Тешләре коелып беткән
Бабасы мине җиңде.
Сораганын бир дә җибәр,
Бүтән көрәшмик инде.

– Улым, менә тимер таяк,
Авырлыгы – чамасыз.
Кырык потка гына бетмәс,
Көчегезне сынашыгыз,
Күккә чөеп карагыз.

Пәри малае кулына
Тимер таякны ала;
Егет янына чыга да
Болай дип әйтеп сала:

– Агай, тагын бер мәртәбә
Сынашып карыйк инде,
Кырык потлы шул таякны
Башлап кем һавага чөя,
Шобага салыйк инде.

Кем биегрәк чөя ала,
Шул җиңүче санала.
Әгәр бу юлы да җиңсәң,
Сораганыңны бирербез,
Килешү көчендә кала.

Әйтте дә шулай диеп,
Җибәрде күккә чөеп.
Болгап торып чөйгән иде,
Таяк күздән югалды;
Шактый вакыт үткәч кенә
Төшеп җиргә кадалды.

Хәзер инде безнең егет
Таякны кулга ала.
Күккә төбәлеп, нигәдер
Бер мәлгә туктап кала.

– Агай, нигә ыргытмыйсың,
Хәлең юк мәллә бүтән?
– Ә-ә-нә офыкта бер болыт,
Шул болытның безнең турыга
Килеп җиткәнен көтәм.

Бу таякны олактырам,
Кыстырып шул болытка.
Бу егет абзаң булыр бу,
Исеңдә тот, онытма!

– Зинһар, алай эшли күрмә,
Харап итәсең, агай!
Бу таяктан колак каксак,
Бетерә мине бабай.

Таякны эләктерде дә
Шундук күздән югалды,
Күл төбенә юл алды.

Бабасы янына чапты,
Сулышын алып көчкә;
Түкми-чәчми сөйләп бирде
Ниләр булганын өстә:

– Бабай, җаным, теге адәм
Узынды, тәмам азды.
Таягыбызны болытка
Тагып җибәрә язды.

– Нәрсә эшләргә соң, улым,
Барып чыкмый безнең эш?
Аңа күпме кирәк икән,
Азга риза булыр микән,
Бар, тиз генә белеп төш.

Ул арада безнең егет,
Ышанасыңмы, туган,
Бик тирән бер чокыр казып,
Тишек эшләпәсе белән
Чокырны каплап куйган.

Чыкты малай яр өстенә,
Килде егет янына.
– Әйдә, агай, килешик, – ди.
Ялвара да ялына: –
Күпме сорасаң да сора,
Әйт бәяңне, тартынма.
Башка чарабыз юк безнең,
Риза бөтен шартыңа.

– Менә шушы эшләпәне
Тутырып акча салыгыз.
Сез дә риза, мин дә риза,
Сез исән-сау, мин сәламәт,
Риза булып калыгыз.

Бу сүзләрдән соң шатланып,
Малай күлгә сикерә;
Безнең егет әйткән шартны
Бабасына җиткерә.

Риза булды бабай да,
Зур гына янчыкка салып
Акча бирде малайга.

Бабасы биргән акчаны
Малай кулына алды;
Ярга чыгып, бу егетнең
Эшләпәсенә салды.
Күзләренә ышанмыйча
Куркып, аптырап калды.



Эшләпәнең тишегеннән
Базга коелды акча.
Тагын алып менәргә дип
Юнәлде пәри аска.

Унбиш тапкыр төшеп менгәч,
Ниһаять, чокыр тулды.
Егет әйтте: – Ярар, җитәр,
Минем күңелем булды.

Шул урынны җире белән
Бергә казып ал инде.
Авылыма кадәр илтеп
Мине озатып кал инде.

Кайту күңеллерәк булыр,
Муеныңа атландыр.
Өеңә әйләнеп кайткач,
Миннән бик күп сәлам әйтеп,
Бабаңны да шатландыр.

Бу егеттән котылганга
Пәри шундый шатланды.
Койрык кына күренеп калды,
Артыннан җил дә иярмәс,
Шундук күздән югалды.

Ә егетнең хәлләр әйбәт,
Китек тормыш көйләнде;
Өр-яңа йорт сатып алды,
Бай кызына өйләнде.

Борынгылардан калган сүз:
«Һөнәрле үлмәс, – диләр. –
Акыл белән кәсеп итсә,
Һич кайгы белмәс», – диләр.

Шау-гөр килеп, куанышып,
Туй ясадылар зурлап.
Кунаклар канәгать калды,
Һичкем сөйләмәс хурлап.

Ул туйда бит мин дә булдым,
Әйтү түгел мактанып.
Бүген бардым, кичә кайттым
Агач атка атланып.

Кыстый-кыстый сыйладылар,
Бик тә юмарт иделәр;
Мичкәдәге ачы балны
Чүмеч белән бирделәр.

Бик кунакчыл иделәр,
Яраттылар, сөйделәр,
Күчтәнәчләр бирделәр.
Озатканда шул чүмечнең
Сабы белән төйделәр.





АЮ БЕЛӘН ТӨЛКЕ

(Әкият-поэма)

Борын-борын заманда,
Башы тишек команда;
Берәү алдап, икенчеләр
Авыз ачып калганда,

Әллә нинди сәер хәлләр,
Мәзәк хәлләр булган, ди,
Урманнарга киек кошлар,
Ерткыч җанвар тулган, ди.

Гадәтләре, холыклары
Төрледән-төрле икән.
Кайсы усал, кайсы шаян,
Кайсы мәкерле икән.

Кайсы ахмак, кайсы зирәк,
Кайсысы шыр дивана.
Алдакчылар, хәйләкәрләр
Бар икән, ди, арада.

Аю Әппәз, Алдар Төлке
Бергә гомер иткәннәр.
Тапкан – бергә, капкан – бергә,
Шулай дөнья көткәннәр.

Аю таза, яшь чагында
Тамаклары тук икән.
Торган куышлары җылы,
Кайгылары юк икән.

Рәхәт заманнар тиз узган,
Көн артыннан көн үткән.
Туннар тузган, гомер узган,
Аю картаеп киткән.

Картлык баскан, көче беткән,
Юньләп күрми күзләре.
Бил бөгелми, аяк сызлый,
Тотмый икән тезләре.

Тешләр төшкән, тырнаклар юк,
Катыланган колакка.
Аугa чыккач, үзе чак-чак
Эләкмәгән тозакка.

Ярый әле дус вакытта
Бераз запас җыйганнар.
Бер тәпән бал, бер тәпән май
Җыеп яшереп куйганнар.

Картайгачтын бергә-бергә
Ашарга ниятләре.
Гомер буе интекмичә
Яшәргә теләкләре.

Хәйләкәрлеге Төлкенең
Мәгълүм иде һәркемгә.
Аю дусты гамьсез генә
Йоклап яткан бер төндә,

Бер сүз әйтмичә дустына
Үз нияте турында,
Шыпырт кына чыгып китә
Бал яшергән урынга.

Аю иртән уяна да
Башын кашып уйлана:
«Кая киткән соң бу Төлке,
Тагын ниләр кылана?»

Иртән кайтып керә Төлке,
Ул кыяфәтен күрче!
Аю сорый: – Кайда йөрдең,
Дөресен сөйләп бирче?!

– Әппәз абый, җанкисәгем,
Сөйлим сиңа дөресен.
Бер генә сүз ялган әйтсәм,
Шушы телем чересен.

Валлаһи, дим, азык эзләп
Интектем көне буе.
Бер авылга туры килдем,
Ә анда бәби туе.

Бер җиңгәчи бәби тапкан,
Шуңа исем эзлиләр.
Аптырашып, нинди исем
Бирергә дә белмиләр.

Хәлемнән килгән кадәрле
Мин аларга булыштым.
Үзем эзләп, үзем табып
Балага исем куштым.

Аю сорый: – Улмы, кызмы?
Сау-сәламәт туганмы?
– Малай туган. Таза, чибәр,
Гүя Айның тулганы.

– Ә исемен кем дип куштың?
– Башламыш диеп куштым.
Бик әйбәтләп сыйладылар,
Зурлап озатып калдылар.

– Ә миңа соң, дәү абзаңа,
Күчтәнәчең юкмыни?
Синең тамак туйган белән
Минем тамак тукмыни?

– Әппәз абзый, кичерә күр,
Күчтәнәчләр алмадым.
Үзләре белеп бирмәде,
Мин сорарга базмадым.

– Әй, Төлке дус, синең эш шәп,
Өстең бөтен, тамак тук.
Ә мин хәлсез, карыным ач,
Нишләргә дә белгән юк.

Төлке чыгып тирә-юньнән
Калдык-постык юнәтеп,
Зур игелек эшләгән күк,
Дустына бирә кайтып.

Аю, мескен, риза була,
Булмый кая барасың?
Дуслык бозылса, яшәүнең
Җаен ничек табасың?

...Көн артыннан көн үтә,
Аюның хәле яман.
Егәр беткән, тешләр төшкән,
Ябыгып беткән тәмам.

Ә Төлкенең эше җайлы,
Күзләре һаман майлы.
Беркөн тагын сиздермичә,
Аю дусты йоклаганда
Шым гына чыгып тайды.

Бал-май яшергән урынга
Барып шәпләп сыйланды.
Яртысына төшеп җитте –
Нәфесен тыеп тормады.

Таң атуга кайтып керсә,
Аю дус көтеп тора.
Канәгатьсезлек күрсәтеп,
Нык кына тамак кыра.

– Төлке дустым, кайда булдың,
Нигә бик озак йөрдең?
– Азык эзләп изаландым,
Гаҗәеп хәлләр күрдем.

– Йә, йә, сөйлә, зарыктырма,
Нинди хәлгә юлыктың?
– Сиңа ризык эзли-эзли,
Бер авылга юл тоттым.

Шул авылга барып керсәм –
Барысы да шаулыйлар.
Бер абыстай бала тапкан,
Шуңа исем сайлыйлар.

– Ир баламы, кыз баламы?
– Менә дигән ир малай!
– Мине бер дә ияртмисең,
Ярамый, дустым, алай.

– Абзыкаем, мин бит анда
Сыйланам дип бармадым.
Бик үтенгәч исем куштым,
Каршы килә алмадым.

Исем кушкач сыйладылар,
Аш-сулары мул иде.
Төпсез бәлеш, токмачлы аш –
Тәмледән-тәмле инде.

Аю дусның кызыгудан
Селәгәйләре ага.
– Ярый, ярый, сөйләп торма,
Ни исем куштың аңа?

– Сирәк исем булсын диеп,
Яртылаш диеп куштым.
Әгәр тагын җае чыкса,
Калдырмам сине, дустым.

– Рәхмәт сиңа, Төлке дустым,
Матур исем тапкансың.
Бу юлысы кучтәнәчләр,
Бәлки, алып кайткансың?

– Кучтәнәчләр булмады шул,
Саран булды хуҗалар.
Тик борчылма, тиздән үтәр
Безнең баштан нужалар.

Башлар гына исән булсын,
Тамак кайгысы үтәр.
Дуслыгыбыз какшамаса,
Бөтен нәрсә дә җитәр.

Хәзер, абзый, җәһәт кенә
Керим әле әйләнеп.
Әгәр ризык табып кайтсам,
Китәр тормыш җайланып.

...Тирә-юньнән каткан-кипкән
Вак-төякләр юнәтеп,
Алып кайтып, көйләп-чөйләп
Сыйлый дустын юатып.

Нишләсен соң Аю агай,
Ни кылса да юк чара.
Үзе ризык табалмагач,
Риза инде бичара.

– И Аю дус, Аю дус,
Миңа таба кулың суз.
Менә ризык, йә, сыйлан,
Баш тарта күрмә сыйдан.

Шулай диеп алдап-йолдап
Юмалаган, юаткан.
Аю Әппәз аннан-моннан
Тамак ялгап, тынычланып,
Урынына барып яткан.

Көннәр үтә дә үтә,
Аю ябыгып бетә.
Хәлсезләнә, ябыгуның
Чигенә килеп җитә.

Ә Төлке соң, аһ, хәйләкәр!
Алдавын дәвам итә.
Атна үтми, сабыры җитми –
Кәсепкә чыгып китә.

Аю йоклап ятканда,
Кызарып таң атканда,
Шыпырт кына чыгып китә,
Кайта кояш батканда.

Аю, мескен, ни хәл итсен,
Күзен талдырып көткән.
Тамагы ач, үзе хәлсез,
Эче ябышып беткән.

Ә Төлкенең кәефе шәп,
Ялганны әйбәт кора:
– Теге авылга бардым мин,
Гел туры килеп тора –
Зур мәҗлескә дәштеләр,
Бер хатын малай тапкан.
Шуңа исем кушып кайттым –
Оста бит мин һәр яктан.



– Ә исемен кем дип куштың?
– Төпләмеш булды инде.
Гел китә дә югала дип
Әрләмәсәнә мине.

– Ә кучтәнәчең юкмыни?
– Бар, менә, сыйлыйм сине.
Үпкәләмәсен, диделәр,
Бик күп булмады инде.

Аю рәхмәт әйтеп алган
Калган ипи катысын.
Ачка үлми калмыйм дисәң,
Алмый кая барасың?

Көннән-көн азына Төлке,
Чыгып китә, югала.
Аю, мескен, карыны ач –
Ыңгыраша, сызлана.

Аю тәмам эштән чыгып,
Бөтенләй хәле беткәч,
Әйтә беркөнне Төлкегә:
– Сүзем бар сиңа, иптәш.

Төлке дустым, синең белән
Бал да май җыйган идек,
Кара көндә ашарбыз дип,
Яшереп куйган идек.

Ачка үлеп булмас инде,
Барып карарга кирәк.
Бозыла башламаганмы –
Татып карарга кирәк.

– Ярый, абзый, мин бик риза,
Барырбыз да карарбыз.
Икәү булгач, сер бирмәбез,
Берәр җаен табарбыз.

Таңнан торып, җитәкләшеп
Чыгып китәләр болар.
Бал яшереп куйган җиргә
Барып җитәләр болар.

Базны ачып карасалар –
Тәпәннән җилләр искән.
Май чиләге дә бушаган,
Һай, каһәр суккан икән!

– Бу базга соң әллә инде
Угрылар төште микән?
Күселәр иялəнгәнме,
Тычканнар эше микән? –



Әй борчыла, өзгәләнә,
Төлкенең хәйлә әзер.
Аю йодрыгын күтәрә:
– Мин сине изәм хәзер!

Көн дә чыгып югаласың,
Үзең ашап бетергән.
Ялганлап бер генә сүз әйт –
Хәзер бәреп үтерәм!

– Әппәз абый, ялганласам,
Менә чәчрәпләр китим.
Сине җаным кебек күрәм,
Ничек хыянәт итим?!



Мин исем кушып йөргәндә,
Син үзең килгәнсеңдер.
Төлке дустың бу эшеңне
Сизенмәс дигәнсеңдер.

Аюның тыны кысыла,
Нәрсә әйтергә белми.
Төлке аның уфтануын
Колагына да элми.

Үзе сөйли, үзе шунда
Хәйлә тозагын кора.
– Йә, алайса мине тыңла,
Эш менә болай тора:

Кем ашаган балны-майны,
Шуның исемен атыйк.
Хакыйкатьтән булмый качып,
Корсакларыбызны ачып,
Кояшка карап ятыйк.

Кем ашаса – корсагыннан
Бал-майлар чыгар эреп.
Мине бәреп үтергәнче,
Гаеплене тап элек.

Төлке әйткәнчә эшлиләр,
Татулыкка ни җитә?!
Хәлсез Аю яту белән
Тәмләп йоклап та китә.

Төлке азгын, оятсыз соң,
Тәмам намусын җуя.
Аю дусты корсагына
Калдык-постык балны, майны
Әйбәтләп сылап куя.

Аннан Аюны уята:
– Тор, күз салчы үзеңә,
Ышанмаган булган идең
Минем әйткән сүземә.
Әнә урлашып ашаган
Майларың чыккан агып.
Фаш ителде караклыгың –
Башка ни кирәк тагын?!

Әппәз абзый, син үзеңнән
Эзлә инде гаепне.
Дуслыгыбыз бетте хәзер,
Нишлим, үзең гаепле!

Алдар Төлке Аю дустын
Шулай ташлый да китә.
Кызганыч, әкиятебез
Шушы урында бетә.

Тик, дусларым, шаккатмагыз –
Бүген безнең арада
Мондый хәлләр очрап тора
Кая гына карама.

Һәр әкияттә гыйбрәт була,
Колак сал син әзрәк.
Дус сайласаң, үзеңнән дә
Булсын, диләр, шәбрәк.

Алдакчылар, хәйләкәрләр
Арабызда җитәрлек.
Дустың булса тугры булсын,
Гадел булсын, гомер юлын
Хыянәтсез үтәрлек.

ЭЧТӘЛЕК

ПӘРИЛЕ КҮЛ БУЕНДА *(Әкият-поэма)* . . . 3

АЮ БЕЛӘН ТӨЛКЕ *(Әкият-поэма)* . . . 25

Литературно-художественное издание
для детей младшего школьного возраста

Халим Заляй
(**Залялов** Халим Бадриевич)

У ЧЕРТОВА ОЗЕРА

Сказки-поэмы

Казань. Татарское книжное издательство. 2006
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма
Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

Хәлим Җәләй
(**Җәләлов** Хәлим Бәдри улы)

ПӘРИЛЕ КҮЛ БУЕНДА

Әкият-поэмалар

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректоры *Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.04.2006. Форматы 60×90 1/8. Офсет кәгазе. «Mysl» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 5,0. Шартлы буяу-оттиск 22,0. Нәшер-хисап табагы 3,82.
Тиражы 5000 д. Заказ З-318.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
http://www.tatarstan.ru/books/
E-mail: tki@books.kazan.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ,
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.